ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

05.10.2018 Казан ш. № 6-149/тп

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2018 ел өчен кушыла торган җылылык йөкләнеше куәте бирәмлегендә исәпләгәндә, «Казэнерго» Акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына кушылу (технологик тоташу) өчен түләүне билгеләү турында» 2017 елның 1 декабрендәге 6-185/тп номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү сферасында бәяләр оештыру турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 нче,»Җылылык белән тәэмин итү системаларына кушылу (технологик тоташу) турында, җылылык белән тәэмин итү сферасында хезмәт күрсәтүләргә дискриминациясез үтә алу турында, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм үз көчен югалтуын тану турында» 2018 елның 5 июлендәге 787 нче карарларына, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Җылылык белән тәэмин итү сферасында көйләнелә торган бәяләр (тарифлар) исәпләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 нче боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында Нигезләмәгә ярашлы, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты БОЕРА:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2018 ел өчен кушыла торган җылылык йөкләнеше куәте берәмлегендә исәпләгәндә, «Казэнерго» Акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына кушылу (технологик тоташу) өчен түләүне билгеләү турында» 2017 елның 1 декабрендәге 6-185/тп номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

тиешле килештәге «кушымта» сүзен тиешле килештәге «1 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Әгәр кушылу өчен техник мөмкинлекләр булып, гариза бирүченең объектына

кушыла торган җылылык йөкләнеше сәгатенә 1,5 Гкал дән артып китсә, кушыла торган җылылык йөкләнеше куәте берәмлегендә исәпләгәндә, «Казэнерго» Акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына кушылуы (технологик тоташуы) өчен түләүне әлеге карарга теркәлгән 2 нче кушымтага ярашлы рәвештә билгеләргә.»;

кушымтаның номер бирелә торган исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
2017 елның 1 декабрендәге 6-185/тп
номерлы боерыгына
1 нче кушымтасына

түбәндәге эчтәлекле икенче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
2017 елның 1 декабрендәге 6-185/тп
номерлы боерыгына
2 нче кушымта

Кушылу өчен техник мөмкинлекләр булып, гариза бирүченең объектына кушыла торган җылылык йөкләнеше сәгатенә 1,5 Гкал дән артып киткән очракта, кушыла торган җылылык йөкләнеше куәте берәмлегендә исәпләгәндә, «Казэнерго» Акционерлык җәмгыятенең җылылык белән тәэмин итү системасына кушылу (технологик тоташу) өчен түләү

мең сум/Гкал/сәг. (ӨКСны исәпкә алмаганда)

| т/б № | Исеме | Күрсәткеч |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүчеләрнең объектларын кушу буенча гамәлләр үткәрү чыгымнары ($П_1$) | 4,726 |
| 2 | Гариза бирүче объектларының кушыла торган җылылык йөкләнеше, кушуның техник мөмкинлекләре булганда, 1,5 Гкал/сәг. тән артып киткәндә, гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яки җылылык энергиясе чыганакларыннан әлеге объектларны кушу ноктасына кадәр җылылык челтәрләрен төзү (реконструкцияләү) (җылылык пунктларын төзүне (реконструкцияләүне) кертмичә) чыгымнары, ($П_{2.2}$), шул исәптән: | |
| 2.1 | Җир өстеннән (җир астыннан) сузу | |
| 2.1.1 | 50 - 250 мм | - |
| 2.1.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.1.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.1.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.1.5 | 701 мм һәм зуррак | - |
| 2.2 | Җир астыннан сузу, шул исәптән: | |
| 2.2.1 | канал ясап сузу | |
| 2.2.1.1 | 50 - 250 мм | 2 873,851 |
| 2.2.1.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.2.1.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.2.1.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.2.1.5 | 701 мм һәм зуррак | - |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2.2 | каналсыз сузу | |
| 2.2.2.1 | 50 - 250 мм | - |
| 2.2.2.2 | 251 - 400 мм | - |
| 2.2.2.3 | 401 - 550 мм | - |
| 2.2.2.4 | 551 - 700 мм | - |
| 2.2.2.5 | 701 мм һәм зуррак | - |
| 3 | Гариза бирүче объектларының кушыла торган җылылык йөкләнеше, кушуның техник мөмкинлекләре булганда, 1,5 Гкал/сәг артып киткәндә, гамәлдәге җылылык челтәрләреннән яки җылылык энергиясе чыганакларыннан әлеге объектларны кушу ноктасына кадәр җылылык пунктларын төзү (реконструкцияләү) чыгымнары, ($П_{2.2}$) | - |
| 4 | Табышка салым | -» |

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов